**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 февраль № 76

г. Казань

2015 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 ел, 26 июль, ТРЗ-43 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2015 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\76.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 10 февраль, 76 нчы
карары белән расланды

# 2015 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

## I бүлек.
## 2015 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләре

2015 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы), Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең төп бурычларын исәпкә алып, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 ел, 21 декабрь, ФЗ-178 нче Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 ел, 26 июль, ТРЗ-43 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде.

2015 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) тормышка ашыруның төп максаты булып Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк һәм керемлерәк булуын тәэмин итү тора.

Татарстан Республикасын икътисадый үстерүдәге өстенлекләрне исәпкә алып, 2015 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

җитештерү-инновация структураларына инвестицияләр җәлеп итү;

дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен формалаштыру.

Югарыда күрсәтелгән бурычларны хәл итү кысаларында 2015 елда акционерлар җәмгыятьләренең Татарстан Республикасы милкендә булган акцияләрен ачык аукцион торгларында реализацияләү планлаштырыла.

2015 елда хосусыйлаштырудан Татарстан Республикасы бюджетына 7 млн.сум күләмендә керемнәр алыныр дип көтелә.

Бу фараз планына (программасына) кертелгән һәм финанс елы үткәннән соң хосусыйлаштырылмаган дәүләт мөлкәте чираттагы финанс елында хосусыйлаштырылырга тиеш.

2 бүлек.
Хосусыйлаштырылуы 2015 елда планлаштырыла торган
Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте

Акцияләрен 2015 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган
акционерлар җәмгыятьләре исемлеге

| Акционерлар җәмгыяте исеме | «Алтын акция» булу-булмау | Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше, % | Акцияләрнең хосусыйлаш-тырыла торган пакеты (өлеше), % |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | | | |
| «Нижнекамскресурсы» ачык акционерлар җәмгыяте | юк | 11,99 | 11,99 |
| «Түбән Кама шин» ачык акционерлар җәмгыяте | бар | 0,196 (гади акцияләр) | 0,196 |
| | | 0,00017 (өстенлекле акцияләр) | 0,00017 |
| «Казан оптика-механика заводы» ачык акционерлар җәмгыяте | бар | 0,277 (өстенлекле акцияләр) | 0,277 |
| Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | | | |
| «Крутушка шифаханәсе» ачык акционерлар җәмгыяте | юк | 19,27 | 19,27 |
| Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | | | |
| «Алабуга икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлар җәмгыяте | бар | 7,69 | 7,69 |
| «2 нче Бөгелмә икмәк продуктлары комбинаты» ябык акционерлар җәмгыяте | юк | 25% + 1 акция | 25% + 1 акция |
| «Бөгелмә элеваторы» ябык акционерлар җәмгыяте | юк | 25% + 1 акция | 25% + 1 акция |
| Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы | | | |
| «Химия технологияләре өлкәсендә инжиниринг төбәк үзәге» ачык акционерлар җәмгыяте | юк | 99,45 | 49,44 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы | | | |
| «Дербышки» 9 нчы стоматология поликлиникасы» ачык акционерлар җәмгыяте | юк | 48,41 | 48,41 |
| Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | | | |
| «Юл» кунакханәсе» ачык акционерлар җәмгыяте | юк | 100 | 100 |
| «АК БАРС» БАНК ачык акционерлар җәмгыяте | юк | 15,31 | 0,99 |

---